**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «10» ноябреннән № 38-311

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17-135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында», 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» , 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законнанар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17 - 135 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-271 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
2021 елның 29 декабрендәге 17-135 нче
номерлы карары белән расланган Татарстан
Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы территориясендә автомобиль
транспортында һәм юл хуҗалыгында
муниципаль контроль турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының
2023 елның 10 ноябрендәге 38-311 номерлы
карары редакциясендә)

Исемлек

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планнан тыш контроль чаралар үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Муниципаль контроль объектында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында һәм (яисә) торак пункт чикләрендә бер үк җирле әһәмияттәге юлда утыз календарь көн дәвамында ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте.
2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән белешмәләр нигезендә, контрольдә тотыла торган затның йөртүчеләре тарафыннан кылынган автомобиль транспортында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның биш процентына һәм аннан да күбрәк фактларын бер календарь ел дәвамында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутында бозу факты арту.
3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп, бер календарь ел дәвамында юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санын ике тапкырга һәм аннан да күбрәк тапкырга арттыру.
4. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда контрольдә тотылучы затны билгеләгән яисә файдаланган юл участогында юл-транспорт һәлакәтләренең календарь аена кимендә биш процентка арту.
5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында, яки юл һәм урамнар киселешендә, кешеләр зыян күргән яки яраланган канәгатьләнерлек булмаган юл шартларына бәйле рәвештә, бер төрдәге юл-транспорт һәлакәте килеп чыгу фактлары ачыклану.